| | |
|---|---|
| СОВЕТ БУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

16 сентябрь 2019 ел № 17

Борындык авылы

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Борындык авыл җирлегендә
җирле референдум үткәрү
инициативасы турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә Борындык авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Борындык авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Борындык авыл җирлегендә референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

«Сез, 2020 елда Борындык авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән килешәсезме». Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлешләрдә тотыла:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:*

- Борындык авылындагы буаны ремонтлау, чистарту һәм төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

- Шүширмә авылындагы күперне ремонтлау, моның өчен материаллар

сатып алу.

- Шүширмә авылында балалар мәйданчыгын төзекләндерү һәм монын өчен материаллар сатып алу;

- һәйкәлләрне төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

*г) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:*

- янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм техник запчастьләр сатып алу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында һәм Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://burunduk-kaybici.tatarstan.ru.

3. Карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен күзәтеп торуны үземдә калдырам.

Борындык авыл җирлеге
Кайбыч муниципаль районы
Татарстан Республикасы
Совет рәисе урынбасары — Р. Р. Нигъмәтжанова